**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Дүрт-Мунча авыл җирлегенең Дүрт-Мунча торак пунктында**
**2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**
**гражданнар җыены**

**14.11.2024** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Дүрт-Мунча авыл җирлеге Дүрт-Мунча торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Дүрт-Мунча авыл җирлеге Дүрт-Мунча торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (янган яктырткычларны алыштыру);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Үзәк, Елга аръягы урамнары буенча юлларны ремонтлау).

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә (Дүрт-Мунча авыл җирлеге Уставының 69 п.5 статьясы) Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Дүрт-Мунча авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Дүрт-Мунча авыл җирлеге башлыгы Р.Т.Ситдыйков